**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-09; +7(84396) 4-35-10, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

16.06.2026 №2

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының
«Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча
гавами тыңлаулар башлануы турында

**ХӘБӘРНАМӘ**

**1.** Әлеге хәбәрнамә белән «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре **проекты (алга таба-проект) буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез**.

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- I өлеш. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе;
- II өлеш. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
- III өлеш. Шәһәр төзелеше регламентлары;
- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар;
- Территорияләрнең махсус шартлары булган зоналарның чикләре картасы.

**3. Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча ачык тыңлаулар 2026 елның 16 июненнән 2026 елның 1 июленә кадәр үткәрелә. Ачык тыңлаулар үткәрү процедурасы түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып тора:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**5. Гавами тыңлаулар уздырыла торган территория:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге.

**6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

- ТР, Чирмешән районы, Күтәмә авылы, Клуб ур., 1а йорты – 16.06.2026 ел

**7. Проект экспозициясен үткәрү сроклары:**

2026 елның 16 июненнән 2026 елның 30 июненә кадәр

**8. Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**

эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш тәнәфесе -12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

**9. Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

2026 елның 16 июненнән 2026 елның 30 июненә кадәр гавами тыңлауларда катнашучылар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба-РФ ГрК) $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт аша;
- язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлауларны оештыручы адресына-Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты, адресы: 423100, ТР, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Совет урамы, 32 йорт, тел. (84396) 2-54-49 (8:00 дән 17:00 гә кадәр);
- гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: 423110, ТР, Чирмешән районы, Күтәмә авылы, Клубная ур., 1а йорты (8:00 дән 17:00 гә кадәр).

РФ ГрК $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**10. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча ачык тыңлауларны 2026 елның 1 июлендә түбәндәге адрес буенча үткәрергә:

- ТР, Чирмешән районы, Күтәмә авылы, Клубная ур., 1а йорты, 10 сәгать 00 минутта.

**11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында 2026 елның 17 июненнән башлап урнаштырылачак (cheremshan.tatarstan.ru) «Район тормышы - Тематик бүлекләр – Гавами тыңлаулар (Иҗтимагый фикер алышулар) - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре вкладкасында (https://cheremshan.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-7611589.htm ).

**12. Әлеге хәбәрнамәне** Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

Башкарма комитет<br>җитәкчесе И.М. Җамалетдинов